ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

№ 969

27.11.2018

***Постановление*** ***Карар***

“Җәмәгать тәртибен саклауда актив
катнашкан өчен” премия турында

Татарстан Республикасының 2015 елның 16 гыйнварендa кабул ителгән “Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашулары турында”гы 4нче номерлы Законы нигезендә, Чистай муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы халык дружинасы әгъзаларын бүләкләү максатында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының “Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен” премия турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Чистай муниципаль районының финанс-бюджет палатасына премияне район бюджеты хисабына түләү өчен акча табуны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренең рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru веб-адресы һәм “Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталын”да “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырып, халыкка белдерергә.
4. Әлеге карарны үтәүгә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан  Республикасы Чистай
муниципаль районы башкарма
комитеты  карарына
кушымта
27.11.2018 ел, № 969

**Татарстан  Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының “Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен” премиясе турындагы  Нигезләмә**

1. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының  “Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен” премиясе (алга таба - премия) җәмәгать тәртибен  саклауны тормышка ашыруда  катнашучы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының ирекле халык дружинасы  ( алга таба –ИХД) әгъзаларын  бүләкләү максатында бирелә.

2. Премия елга бер тапкыр район бюджетының беренче ярты еллыгы йомгаклары буенча, Чистай муниципаль районында хокук бозуларны кисәтү буенча Комплексды программаның 5.1 пункты нигезендә бирелә.

Премия өч категория буенча бирелә:

- беренче урын өчен ИХД  әгъзаларына бишәр мең сум;
- икенче  урын өчен ИХД  әгъзаларына икешәр мең сум;
- өченче урын  өчен ИХД  әгъзаларына берәр мең сум;

3. Татарстан Республикасының хокук саклау юнәлешендәге җәмәгать берләшмәләре һәм халык дружиналары реестрына  кертелгән Чистай муниципаль районының  халык дружинасы   әгъзалары   премия алуга кандидатлар булып торалар.

4. Премия бирү өчен кандидатка Чистай муниципаль районының  халык дружинасы отряды командиры имза куйган, Россия Эчке эшләр министрлыгының Чистай муниципаль районы бүлеге начальнигы белән килештерелгән  күрсәтмә Татарстан  Республикасы Чистай муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча штабка яртыеллык тәмамланырга 10 көн кала – ел саен 20 июньгә кадәр җибәрелә.

5. Премия бирү өчен кандидатлар Татарстан  Республикасы Чистай муниципаль районында  ирекле халык дружиналарының координацион штабы утырышында  халык дружиналары отрядлары командирлары тәкъдинәре буенча карала.

6. Татарстан  Республикасы Чистай муниципаль районында  халык дружиналарының эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы утырышларда хокук саклау органнары, дәүләт властеның башкарма органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләренең һәм халык дружиналары отрядлары командирларының катнашуы өчен җаваплы.

7. Премия бирү турындагы карар Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында халык дружиналарының эшчәнлеген координацияләү буенча штаб утырышында утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

8. Карар кабул иткәндә түбәндәге критерийлар исәпкә алына:

1) халык дружинасы әгъзасының масса-күләм чаралар уздыруда катнашуы;

2) кизү торуга даими чыгу;

3) административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау;

4) җинаятьне ачуда хокук саклау органнарына ярдәм күрсәтү.

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында халык дружиналарының эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырыш узганнан соң өч көн эчендә тавыш бирүдә катнашкан коорднацион штаб начальнигы, сәркатибе һәм барлык әгъзалары тарафыннан кул куела.